Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2022 елның 11 феврале 95№

Әлки муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турында» 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль-хосусый партнерлык кысаларында җирле үзидарә органнарының, юридик затларның үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу максатында, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2021 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә (2018. 17.12, 206№, 2021.30.04, 51№, 2021.29.07, 60№ ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 бүлекнең 8 пунктчасына «каты коммуналь калдыкларны урнаштыру» сүзләреннән соң «медицина калдыкларын җыю, файдалану, зарарсызландыру, урнаштыру, саклау, транспортировкалау, исәпкә алу һәм утильләштерү» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А.Ф. Никошин